**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 25 ноябре 23 номерлы

"Татарстан Республикасы Сарман
муниципаль районы Иске Минзәләбаш
авыл җирлегенең 2023 елга һәм
2024- 2025 елларга план чорына
социаль-икътисадый үсеш
фаразы турында"

Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Татарстан Республикасының Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, башкарма комитет җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024- 2025 елларга план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» чыгышын тыңлап фикер алышканнан соң, Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024- 2025 елларга план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1нче кушымта).
2. Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024-2025 елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә

Иске Минзәләбаш авыл
җирлеге Советы рәисе А.Н.Габдрахманов

Приложение 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024- 2025 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | хисап | хисап | бәяләмә | фараз | фараз | фараз |
| Халык саны | кеше | 910 | 920 | 920 | 920 | 910 | 910 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 1,01 | 1,01 | 1 | 1 | 0,99 | 1 |
| Мөгезле эре терлекләр саны | баш | 320 | 325 | 325 | 325 | 325 | 325 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 1,03 | 1,02 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Инвестицияләр | мең сум | - | 1800 | 2500 | 2600 | 2700 | 2750 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0 | 1800 | 1,39 | 1,04 | 1,04 | 1,02 |
| Торак тапшыру | кв.м. | 269 | 131 | 200 | 200 | 200 | 200 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0,37 | 0,89 | 0,83 | 1 | 1 | 1 |
| Хезмәткә түләү фонды | мең сум | 92 865,6 | 96 487,4 | 104 688,8 | 116 099,9 | 125 852,3 | 136 046,3 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0,88 | 1,04 | 1,08 | 1,1 | 1,08 | |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум | 33 793,9 | 35 111,9 | 36 810,4 | 40 822,7 | 44 251,9 | 47 836,3 |
| Хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны | кеше | 229 | 229 | 229 | 237 | 237 | 237 |
| Эшкуарлар саны (КФХ,ШЭ) | кеше | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 |
| Эшсезләр саны | кеше | 7 | 5 | 2 | 1 | 1 | 1 |

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге хисапчысы Сафина Г.И.

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024- 2025 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразына аңлатма язуы

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразына керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнарының статьяларын формалаштыру өчен кирәк булган төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала.

2023-2025 елларга Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән 2023-2025 елларга Россия Федерациясе икътисады эшчәнлегенең сценар шартларының база варианты нигезендә эшләнде, Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2022 елның көтелә торган нәтиҗәләрен һәм 2023-2025 елларда икътисад һәм социаль өлкә үсеше тенденцияләрен бәяләүне исәпкә алып, 2023-2025 елларга Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән инфляция һәм индекс-дефляторлар күрсәткечләрен кулланып эшләнде.

2023-2025 елларда «Urals» нефтенә бәяләрнең баррель өчен 61,2-71,4 АКШ доллары дәрәҗәсендә уртача динамикасы фаразлана.

2023 елда долларның уртача еллык курсы АКШ доллары өчен 77,0 сум, 2024 елда АКШ доллары өчен 78,7 сум булыр дип фаразлана. 2025 елда, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы фаразына караганда, доллар курсы АКШ доллары өчен 81,0 сум тәшкил итәчәк.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге составына Иске Минзәләбаш, Кужак авыллары керә.

2023 елга Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегендә халык саны 920 кеше, 2024 елга – 920 кеше, 2025 елга – 910 кеше тәшкил итәчәк.

Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «Җәлил» агрофирмасы ҖЧҖенең булган потенциалын һәм килеп туган үсеш тенденцияләрен, фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, шулай ук «Агросәнәгать комплексын үстерү» һәм «Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» программаларын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнгән.

Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә «Җәлил» агрофирмасы ҖЧҖ, «Земля плюс» ҖЧҖ һәм КФХ Әшрәфуллин И. Р. ,КФХ Сәлимгәрәев Ф. Ф.,КФХ Гарифуллин З. С., КФХ Габдрахманов Р. М. эшчәнлек алып баралар.

2022 елда авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме 688 900 мең сумнан артык тәшкил итәчәк. 2023 ел фаразына караганда, продукция күләме 723 345 мең сум тәшкил итәчәк, 2024 елда – 5% ка артачак һәм 759 512 мең сум тәшкил итәчәк, 2025 елда – 5% ка артачак һәм 797 488 мең сум тәшкил итәчәк.

2022 елда төп капиталга инвестицияләр 0,5 млн. сум күләмендә булды. 2023 елда грантлар хисабына 1,5 млн.сум күләмендә фаразлана, 2024-2025 елда

үсеш темпы 4-5% тәшкил итәчәк һәм 1,6 млн. сум һәм 1,7 млн. сум тәшкил итәчәк.

2023-2025 елларда якынча 400 квадрат метр торак файдалануга тапшыру планлаштырыла.

2022 елда хезмәт хакы фонды 104 688,8 мең сум тәшкил итәчәк.

2023 елга хезмәт хакы фондының фаразланган күрсәткече – 116 099,9 мең сум, 2024 елда – 125 852,3 мең сум, 2025 елда-136 046,3 мең сум тәшкил итәчәк.

Хезмәткәрләр саны уртача 229 кеше тәшкил итә.

2022 елда уртача айлык хезмәт хакы 36 810,4 сум тәшкил итәчәк. 2023 елга фараз буенча ул - 40 822,7 сум, 2024 елда - 44 251,9 сум, 2025 елда 47 863,3 сум тәшкил итәчәк.

2023 елга эшмәкәрләр саны (КФХ) 12 кеше тәшкил итәчәк, 2024 елга-12, 2025 елга-12 кеше.